

Танылган совет һәм Россия педагогы-теоретигы, кончыгыш телләре белгече - востоковед, Россиядә гомуми һәм һонәри белем бирvдә проблемалы укытуга нигез салучыларнын берсе, якташыбыз (1926 елнын 1 маенда Мордовиянен бvгенге Ромоданово районы Алтар- Ләбәжә татар авылында эшче гаиләсендә туган) Мирза Исмәгыйль улы Мәхмvтовнын тууына 100 ел тулды. Без анын белән горурланабыз.
Жиде еллык Алтар мәктәбен һәм Ләмберә тракторчылар курсын тәмамлаганнан сон, Сәмәркand олкәсендә ике ел механизатор булып эшли Мирза Исмаил улы. 1944 елны Совет гаскәренә алына, сугышта катнаша. Сугыш сон хәрби сафта кала. Хәрби разведка институтын тәмамлагач, Балтыйк буе хәрби округында тәржемәче булып тора.      1956 елны хезмәттән киткәч, ул Казанга килә. Казан университетына аспирантурага гарәп теле белгечләренә укырга керә. Аны тәмамлагач (1956-58 елларда) гарәп телен укыта. 1958–1976 елларда Татарстан мәгариф министры булып хезмәт итә. Ә 1976-1992 елларда Мирза Исмаил улы СССР Педагогия фәннәре академиясенен һонәри педагогика фәнни-тикшеренv институтын оештыра һәм 17 ел буена житәкли, һонәри-техник белем бирv мәсьәләләре буенча тикшеренvләр оештыра, гомуми һәм һонәри белем бирvне интеграцияләv принцибын эшли.
1992 елда М.Мәхмvтов Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен оештыручыларынын берсе була. Шул ук елда ул югары уку йортынын яна тибын – Татар-Америка региональ институтын (ТАРИ) този һәм 1995 елга кадәр анын ректоры булып эшли.
2008 елнын 25 мартында Мирза Исмаил улы Мәхмvтов Казанда вафат була.
Мирза Исмаил улынын мирасы 500 дән артык фәнни хезмәтне vз эченә ала. Анын кvп хезмәтләре гарәп, испан, болгар, немец, инглиз, кытай һәм башка телләргә тәржемә ителгән. 1975 елда анын «Проблемное обучение. Основные вопросы теории» дигән фундаменталь хезмәте донья кvрә. «Современный урок» монографиясе (1985) Н. К.

Крупская исемендәге премиягә лаек була. Галимнен сонгы хезмәтләренен берсе – «Ислам доньясы» китабы.
Мирза Исмаил улы Мәхмvтов СССР Педагогия фәннәре академиясе академигы, РАО академигы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенен хакыйкый әгъзасы, Нью-Йорк фәннәр академиясенен академигы булып тора. Ул фәлсәфә фәннәре кандидаты, педагогика фәннәре докторы, профессор. Россия Федерациясенен атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасынын фән олкәсендәге Дәvләт премиясе лауреаты. Анын хезмәтләре югары дәvләт бvләкләре – Ленин һәм Октябрь революциясе орденнары, ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрагы белән «Татарстан алдындагы хезмәтләре очен» ордены, 12 хәрби һәм юбилей медальләре белән бvләкләнгән.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**